ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2024 г. Заинск № 46

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 сентябрендәге 556 номерлы «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, "Реклама турында "Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 сентябрендәге 556 номерлы «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 2.8.2 пунктның 6 пунктчасында «5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләрен «5 нче өлешнең, әгәр реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күп фатирлы йортта бина хуҗаларының гомуми милке кулланылса, 5.1, 5.6, 5.7 өлешләре» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең Икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшкуарлыкка ярдәм итү буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

О.В. Усик
7-14-14